

Егерме оченче гыйнварда безнен илдә беренче тапкыр «Игелекле шимбә» Ботенроссия акциясе старт алды. Анын инициаторлары - «Россия-момкинлекләр иле» Президент платформасы базасында vткәрелә торган «Зур тәнәфес» конкурсында катнашучылар. Алар барлык балаларга һәм аларнын ата-аналарына яна елны игелекле эшләр һәм файдалы гадәтләрдән башларга тәкъдим иттеләр. Бу чарага Торбеево районынын барлык мәктәп укучылары һәм укытучылары жәлеп ителде.

Малайлар һәм кызлар, асылда, гади, әмма кирәкле әйберләр ясап, кулдан килгәннен барысын да эшләделәр. Кvп кенә яшь буын вәкилләре сәламәтләндерv процедура-лары очен саф һавага чыктылар, ботен гаилә очен иртәнге ашлар әзерләделәр, хужалык эшләре белән шогыльләнделәр. Әтиләр һәм бабайлар белән бергә кошлар очен жимлекләр ясадылар, аларны агачларга элделәр. Волонтерлар олкән яшьтәге кешеләр очен ки-беттән кирәк-яраклар сатып алылар, территорияләрне кардан чистартты-лар. Ин актив яшvсмерләр проектны оештыручылардан призлар алачак: термослар, остәл уеннары, пледлар, пикник очен жыелмалар.
«Игелекле шимбә» акциясе кысаларында Темников районы Аксел мәктәбе укучылары ялгыз пенсионерларга һәм ветераннарга ярдәмгә чыктылар.
Поиск отрядында катнашучылар блокадница ишегалдын жыештыруда булыштылар, һәлак булган сугышчылар һәйкәле янындагы территорияне кардан чистарттылар. Аннан сон «Сабый» балалар бакчасында тәрбияләнvчеләргә сюрприз ясадылар: бозда шуу очен тауны тәртипкә кеттеләр, кар ныгытмасын һәм зур кар бабайны ясадылар. Физик эшкә карамастан, «Игелекле шимбә» бик кvп унай эмоцияләр бvләк итте. Ә хезмәт коненнән сон, балаларны конфетлар һәм печеньелар белән кайнар чәй котә иде. Акция традицион булырга момкин һәм атна саен vткәрелер дип котелә.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**